**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «05» сентябреннән №48-364

2024 елда «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру һәм 2025 елга бурычлар

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А.И.Бутинаның 2024 елда «2021-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру һәм 20245 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы А.И.Бутинаның 2024 елда «2021-2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф системасын үстерү» муниципаль комплекслы программасының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру һәм 2025 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә максатчан эш алып барырга:

- үз вакытында кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру, мәктәпкәчә белем биру оешмаларының матди-техник базасын яңарту, белем бирү процессына фәнни-методик ярдәм күрсәтү юлы белән мәктәпкәчә белем бирүнең муниципаль системасын үстерү өчен шартлар тудыру буенча;

- районның мәктәпкәчә оешмаларында тулы канлы тел мохитен булдыру һәм үстерү шулай ук өстәмә белем бирү кысаларында муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүгә ярдәм итү буенча;

- район мәгариф оешмаларында сәламәтлекне саклаучы белем бирү мохитен формалаштыру өчен шартлар тудыру буенча.

- мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартына туры килә торган балалар бакчаларында өстәмә белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гамәлгә ашыру буенча;

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә эшне көчәйтергә:

- мәктәпкәчә белем бирүнең инновацион характерын тәэмин итү буенча;

- туган телне өйрәнүнең сыйфатын күтәрү буенча;

- әхлакый һәм физик яктан сәламәт шәхес формалаштыру өчен шартлар тудыру буенча;

- талантлы һәм сәләтле балалар белән эшләү системасын формалаштыру буенча.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов